| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2017 елның 03 нче феврале** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 170** |

Зеленодольск районы, Осиново авыл җирлеге, Новониколаевский поселогы, Цветочная урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Зеленодольск районы, Осиново авыл җирлеге, Новониколаевский поселогы, Цветочная, урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан, Солидарная урамындагы авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле 21 нче күп фатирлы торак йортның җир кишәрлеген , шулай ук кушымтадагы исемлеккә, кушымтага ярашлы рәвештә күрсәтелгән йортта урнашкан күчемсез мөлкәт объектларны (торак һәм торак булмаган биналарны) тартып алырга (кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:
   - тартып алына торган күчемсез мөлкәт хокукына ия булучыларга;
   - күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;

- «Торак сәясәте департаменты» МКУ .

4. «Зеленодольск муниципаль районының Җир мөлкәте мөнәсәбәтләре палатасы» МУ әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 03 февралендәге
170 номерлы карарына кушымта

Зеленодольск районы, Осиново авыл җирлеге, Новониколаевский поселогы, Цветочная урамы, 21 нче күп фатирлы торак йортта урнашкан авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле күчемсез мөлкәтнең тартып алына торган объектлары (торак, торак булмаган биналар) исемлеге

| № кв. |
| --- |
| 4 |